**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**муниципального**
**образования « Масягутовского**
**сельского поселения»**
ул. Дружба д.12
с. Масягутово, Азнакаевский район, 423311
Тел ( Факс) : (8 – 85592) 38-2-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**“ Мәсгут авыл җирлеге”**
**муниципаль берәмлеге**
**БАШЛЫГЫ**
Дружба урамы, йорт12, Мәсгут авылы,
Азнакай районы,423321
Тел(факс) :(8 –85592) 38-2-16

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«12» ноябрь 2019 ел № 27

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 22 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә: Г.Багманов урамы буенча 1 йорттан 61 йортка кадәр, Дуслык урамы буеча 1 йорттан 55 йортка кадәр, 1 Май урамы буенча 1 йорттан 26 йортка кадәр, 8 Март 1 йорттан 59 йортка кадәр.
2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл жирлеге Мәсгут торак пунктында узара салым керту мәсьәләсе буенча халык жыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл жирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү урыны – Мәсгут авылы, Г.Багманов урамы 16 йорт, Мәсгут авылы мәдәният йорты;

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 12 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Азнакай муниципаль районы, Мәсгут авыл җирлеге, Дуслык урамы, 12 йорт;

- сайлау хокукына ия булган Яхшы-Бай торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Мәсгут торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 200 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Мәсгут авылы юлларын вак таш һәм гравий белән төзекләндерү

- Мәсгут авылы зиратын коймалау

- Мәсгут авылында урам исемнәре язылган табличкалар ясату

- Бәйрәм чараларын оештыру Һәм уткәру (Яна ел, Җиңу көне, Сабантуй, Халыкара өлкәннәр көне)

« РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мәсгут авылы, Дуслык ур., 12 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: Э.Ә.Габдрахманов